КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 1 сентябрь г.Казань № 805

2021 елда мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләр өчен татар теленә өйрәтү буенча укыту-методик комплектлар бастырып чыгаруга бәйле чыгымнарны каплау өчен юридик затка субсидия бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләре үз көчен югалкан дип тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2021 елда мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләр өчен татар теленә өйрәтү буенча укыту-методик комплектлар бастырып чыгаруга бәйле чыгымнарны каплау өчен юридик затка субсидия бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 1 сентябь, 805 нче
карары белән расланды

## 2021 елда мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләр өчен татар теленә өйрәтү буенча укыту-методик комплектлар бастырып чыгаруга бәйле чыгымнарны каплау өчен юридик затка субсидия бирү тәртибе

### I. Гомуми нигезләмәләр

1. Бу Тәртип 2021 елда мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләр өчен татар теленә өйрәтү буенча укыту-методик комплектлар бастырып чыгаруга бәйле чыгымнарны каплау өчен юридик затка субсидия (алга таба – субсидия) бирү максатларын, шартларын һәм механизмнарын билгели.

2. Субсидия бирү «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2020 елның 27 ноябрендәге 78-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм 2021 елда бу Тәртипнең 4 пунктында билгеләнгән максат өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына (алга таба – Министрлык) бюджет акчасын алучы буларак билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

Министрлык, Татарстан Республикасы бюджеты турындагы закон проектын (Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законга үзгәрешләр кертү турындагы закон проектын) формалаштырганда, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында субсидия турында мәгълүматлар урнаштыра.

3. Бу Тәртиптә аны куллану максатларында түбәндәге терминнар кулланыла:

оешма – үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыручы, субсидия алу өчен сайлап алуда катнашуга заявка (алга таба – заявка) бирүче дәүләт (муниципаль) унитар предприятиесе булган юридик зат;

субсидия алучы – сайлап алу йомгаклары буенча субсидия бирү турында карар кабул ителгән оешма.

### II. Субсидия бирүнең максаты

4. Субсидия бирүнең максаты – мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләр өчен татар теленә өйрәтү буенча укыту-методик комплектлар бастырып чыгаруга бәйле чыгымнарны каплау.

### III. Субсидия бирүнең шартлары

5. Субсидия бирүнең шарты – оешманың Министрлык тарафыннан оештырыла торган сайлап алуда җиңеп чыгуы.

6. Сайлап алуны үткәрү ысулы – оешманың сайлап алу критерийларына туры

килүеннән һәм заявкалар керү чиратыннан чыгып, Министрлык тарафыннан заявкалар нигезендә субсидия алучыны билгеләүдән гыйбарәт тәкъдимнәр соратып алу.

## IV. Сайлап алуны үткәрү тәртибе

7. Сайлап алу Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Заявкаларны сайлап алуны үткәрү сроклары, кабул итү сроклары, заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты Министрлык боерыгы белән раслана.

8. Министрлык, сайлап алу башлану датасына кадәр биш календарь көннән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында һәм үзенең рәсми сайтында, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән ким булмаган сайлап алуны үткәрү срокларын (заявкалар бирү (кабул итү) башлану (тәмамлану) датасын һәм вакытын);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

бу Тәртипнең 23 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин итеlә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 9 пункты нигезендә оешмаларга карата таләпләрне һәм әлеге таләпләргә туры килүне раслау өчен оешмалар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 11 пункты нигезендә бирелә торган заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 14 – 19 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

оешмаларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану вакытын;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) куелырга тиешле имза кую вакытын;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

сайлап алу нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмаган урнаштыру датасын.

9. Оешма сайлап алу үткәрелергә планлаштырыла торган ай алдыннан килгән айның беренче көненә түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

оешманың салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары

нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар һәм процентлар түләү буенча башкарылмаган йөкләмәсе булмау;

оешманың Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрне, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы каршында акчалата йөкләмәләр буенча үз вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычы булмау;

оешма үзгәртеп оештыру (оешмага башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәү, оешманың эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмау;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкчеләр, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер кеше башкара торган башкарма орган функциясен үтәүче зат яки оешманың баш бухгалтеры турында мәгълүматлар булмау;

оешма чит ил юридик заты, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит илләр юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артмаган Россия юридик заты булмау;

оешма бу Тәртипнең 4 пунктында билгеләнгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмау.

10. Сайлап алу критерийлары:

оешманың төп эшчәнлек төре булып нәшрият эшчәнлеге тора;

оешманың нәшрият эшчәнлеге өлкәсендә заявка биргән көнгә кимендә 5 ел эш тәҗрибәсе булу;

оешма тарафыннан мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләр өчен татар телен өйрәтү буенча укыту-методик комплектлар бастырып чыгару.

11. Сайлап алуда катнашу өчен оешма Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

үз эченә шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә оешма турындагы, оешма бирә торган заявка турындагы мәгълүматны, тиешле сайлап алуга бәйле булган оешма турындагы башка мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгын ала торган һәм бу Тәртипнең кушымтасында бирелгән формада булган заявка;

гамәлгә кую документларының, шулай ук аларга кертелә торган барлык үзгәрешләр турындагы документларның күчермәләрен;

оешманың бу Тәртиптәге 9 пунктның өченче – җиденче абзацларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында булган һәм оешма җитәкчесе тарафыннан имза куелган белешмә кәгазен;

Федераль салым хезмәтенең территориаль бүлекчәсендә салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар һәм процентлар түләү буенча

бакарылмаган йөкләмәләре булмау турында алынган белешмә кәгазен;

мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен татар телендә укыту-методик комплектлар, дидактик һәм башка материаллар бастырып чыгару буенча эшчәнлек тәҗрибәсе булуы турында булган һәм оешманың җитәкчесе тарафыннан имза куелган мәгълүмати белешмә кәгазен;

бу Тәртипнең 4 пунктында билгеләнгән максат өчен чыгымнарның оешма җитәкчесе тарафыннан расланган һәм финанс-икътисадый нигезләве теркәлгән сметасын;

мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләр өчен татар теленә өйрәтү буенча укыту-методик комплектлар бастырып чыгаруга тотылган чыгымнарны раслый торган документларның оешма җитәкчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре (шартнамәләр, башкарылган эшләр актлары, йөкнамәләр, түләү йөкләмәләре).

Бер оешма бер генә заявка бирергә мөмкин.

12. Бу Тәртипнең 11 пунктындагы бишенче абзацында күрсәтелгән документ оешма тарафыннан тапшырылмаган очракта, Министрлык мәгълүматны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

13. Министрлыкка кергән заявка кергән көненнән бер эш көне эчендә теркәлә. Заявкалар, керү датасына һәм вакытына карап, чират тәртибендә тәртип саны бирелеп теркәүгә алына.

Заявка биргән оешманың вәкаләтле вәкиленә, заявканы алу датасын һәм вакытын күрсәтеп, заявка алу турында расписка бирелә, аңа Министрлыкның заявканы кабул итеп алган вазыйфаи заты тарафыннан имза куела.

Заявка почта элемтәсе аша кергәндә заявканы алу турында расписка язылмый, заявканы теркәүгә алу датасы итеп Министрлык тарафыннан почта юлламасы алынган һәм почта юлламасында штемпель белән расланган дата күрсәтелә.

Заявка электрон формада кергәндә заявканы теркәүгә алу датасы итеп оешмадан Министрлыкка кергән документка Министрлык тарафыннан тәртип буенча керү саны бирелгән дата алына.

Заявка оешма тарафыннан аларны кабул итү вакыты тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алынырга мөмкин. Заявкага үзгәреш кертү яки аны кире алу турында хәбәрнамә, әгәр дә аңа үзгәреш кертү оешма тарафыннан яңа заявка бирү юлы белән гамәлгә ашырылса яки аны кире алу турында хәбәрнамә Министрлык тарафыннан заявкалар бирү срогы чыкканга кадәр алынса, гамәлдә дип санала.

Заявка кире алынганда оешманың Министрлыкка кергән документлары кире кайтарылмый.

14. Заявкаларны кабул итә башлау һәм төгәлләнү сроклары, заявкаларны карап тикшерү графигы Министрлык боерыгы белән раслана, шул ук вакытта заявкаларны карап тикшерә башлау датасы заявкаларны кабул итү срогының соңгы көненә туры килгән яки аннан иртәрәк булган дата була алмый.

15. Заявкаларны карап тикшерү максатларында Министрлык тарафыннан заявкаларны карап тикшерү комиссиясе (алга таба – комиссия) төзелә. Комиссия Министрлык хезмәткәрләре арасыннан составы кимендә биш әгъзадан (рәисне кертеп) торган итеп төзелә.

Комиссия эше утырышларда башкарыла. Комиссия утырышы, әгәр анда кимендә өч әгъза катнашса, тулы хокуклы дип санала.

Комиссия заявкаларны кабул итү срогы чыккан көннән килә торган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә:

заявкаларны кергән чираты нигезендә, шулай ук оешмаларның бу Тәртипнең 9 һәм 10 пунктларында билгеләнгән сайлап алу критерийларына һәм таләпләренә туры килү-килмәвен карап тикшерә;

бу Тәртипнең 16 пунктында билгеләнгән нигезләр булганда заявкаларны кире кагу турында карар кабул итә;

сайлап алуда җиңүчене билгеләү турында карар кабул итә, ул комиссия утырышы үткәрелгән көндә комиссия утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә һәм комиссия рәисе һәм секретаре тарафыннан имза куела.

Комиссия карарлары комиссия утырышында катнашучы әгъзаларның күпчелек тавышы белән ачык тавыш биреп кабул ителә. Тавышлар тигез булганда рәис тавышы хәлиткеч була.

Комиссия утырышының беркетмәсе аңа имза куелган көнне Министрлыкка җибәрелә.

16. Заявкаларны карап тикшерү стадиясендә заявканы кире кагу өчен түбәндәгеләр нигез була:

оешманың бу Тәртипнең 9 һәм 10 пунктларында билгеләнгән сайлап алу таләпләренә һәм критерийларына туры килмәве;

оешма тарафыннан тапшырылган заявканың һәм документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән заявкаларга карата таләпләргә туры килмәве;

оешма тарафыннан бирелгән мәгълүматның, шул исәптән юридик затның урнашу урыны һәм адресы турындагы мәгълүматның дөрес булмавы;

оешма заявканы аларны кабул итү вакыты тәмамлану датасыннан һәм (яки) вакытыннан соң бирү.

17. Министрлык комиссия утырышы беркетмәсе кергән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә сайлап алуда җиңүчегә субсидия бирү турында карар кабул итә.

Сайлап алуда җиңүчегә субсидия бирү турындагы карар Министрлык боерыгы белән раслана.

18. Бу Тәртипнең 15 һәм 17 пунктларында күрсәтелгән һәм кабул ителгән нәтиҗәләре турындагы хәбәрнамәләр Министрлык тарафыннан оешмаларга тиешле карарлар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә язма рәвештә җибәрелә.

19. Министрлык, сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган бишенче календарь көннән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында һәм үзенең рәсми сайтында заявкаларны карап тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыра:

заявкаларны карап тикшерүне үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән оешмалар турында мәгълүмат;

заявкалары кире кагылган оешмалар турында мәгълүмат (аларны кире кагу сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләрне күрсәтеп);

килешү төзелә торган субсидия алучының исеме һәм аңа бирелә торган субсидиянең күләме.

## V. Субсидияне исәпләп чыгару һәм бирү тәртибе

20. Субсидиянең күләме мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләр өчен татар теленә өйрәтү буенча укыту-методик комплектлар бастырып чыгаруга бәйле чыгымнарны каплау өчен Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләр өчен татар теленә өйрәтү буенча укыту-методик комплектлар бастырып чыгару өчен оешма тарафыннан тотылган чыгымнарны исәпкә алып билгеләнә.

Субсидия күләме (С) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$С = Е_1 + Е_2 + Е_3 + Е_4 + Е_5 + Е_6,$$

монда:

$Е_1$, $Е_2$, $Е_3$, $Е_4$ – бу Тәртипнең 21 пунктындагы икенче – бишенче абзацларында күрсәтелгән юнәлешләр буенча фактта тотылган, вәкаләтле орган тарафыннан бердәй (бертөрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) булган җитештерүче оештыручыларның бәяләре турындагы, бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән билгеләнә торган чыгымнар күләме, сум;

$Е_5$ – Россия Федерациясе Пенсия фондына, Россия Федерациясенең Мәҗбүри медицина иминияте фондына, Россия Федерациясенең Социаль иминият фондына бюджеттан тыш фондларга иминият кертемнәрен, җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминләштерү кертемнәрен, дәүләт пошлиналарын, законнарда билгеләнгән тотып калып күчерелә торган акча күләмнәре нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри күчерүләрне һәм түләүләрне түләү өчен фактта тотылган чыгымнар, сум;

$Е_6$ – штаттагы һәм штаттан тыш хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә фактта тотылган, вәкаләтле орган тарафыннан дәүләт статистикасы органнарында булган эш хакы дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны, оешма белән бертөрле эшчәнлек гамәлгә ашыручы юридик затларда, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында (эш бирүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) эш хакы дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән билгеләнә торган, әмма хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән минималь күләменнән түбән булмаган чыгымнар, сум.

21. Субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлешләре исемлеге:

басмаларның макетын әзерләүгә һәм редакция хезмәтләре күрсәтүгә, шул исәптән хезмәтләр күрсәтүгә тиешле шартнамәләр буенча чыгымнар;

авторлык һәм чиктәш хокуклар буенча түләүләр (архив материалларыннан, компьютер графикасыннан файдалану чыгымнарыннан тыш);

типография һәм полиграфия хезмәтләре, басмаларны илтеп бирү (ташу) чыгымнары өчен түләү;

канцелярия һәм чыгым материаллары, инвентарьлар, җиһаз өчен комплектлау һәм чыгым өлешләрен сатып алуга, шул исәптән җиһазларны ремонтлауга чыгымнар;

штаттагы һәм штаттан тыш хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү;

бюджеттан тыш фондларга иминият кертемнәрен, җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминләштерү кертемнәрен, дәүләт пошлиналарын, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри күчерүләрне һәм түләүләрне түләү.

22. Субсидия алучылар субсидия керү һәм аны тоту буенча аерым бухгалтерлык исәбен алып бара.

23. Субсидия бирүнең нәтиҗәсе – Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләр өчен татар теленә өйрәтү буенча методик ярдәмлекләрне, күрсәтү һәм тарату материалларын үз эченә алган кимендә җиде укыту-методик комплектының һәрберсен кимендә 1000 нөсхәдә бастырып чыгару һәм агымдагы елның 1 декабренә кадәр тәэмин итү.

24. Субсидия бирү өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасы нигезендә, Министрлык тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән җиде эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлык белән субсидия алучы тарафыннан төзелә торган килешү нигез була.

25. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия бирү максаты;

субсидия күләме;

субсидияне күчерү сроклары һәм тәртибе;

субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе;

субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе;

субсидияне кире кайтару очраклары һәм тәртибе;

субсидияне мәҗбүри түләтү чараларын кабул итү сроклары;

субсидия бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен бозган өчен җаваплылык;

субсидия алучының, шулай ук субсидия алучылар (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләрдән, үзләренең устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнаша торган хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләрдән, шулай ук устав (җыелма) капиталларында шундый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнаша торган коммерцияле оешмалардан тыш) белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның аларга карата Министрлык тарафыннан тикшерү үткәрүгә һәм дәүләт финанс контроле органы тарафыннан субсидия бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен үтәүгә карата муниципаль финанс контролен башкаруга ризалыгы;

Килешүләрнең бертип формаларына теркәлә торган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән формалар буенча килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзү шарты һәм тәртибе;

бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән, элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары Министрлыкка киметелгән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча килешүгә ирешеп булмаганда килешүне өзү турында, субсидияне килешүдә билгеләнгән күләмдә бирү мөмкин булмавына китерә торган шарт.

26. Субсидия, сайлап алуда җиңүчегә субсидия бирү турындагы карарны Министрлык кабул иткән көннән соң килә торган 10 эш көненнән дә соңга калмыйча,

Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениесендә яки кредит оешмасында субсидия алучы тарафыннан ачылган субсидия алучының исәп-хисап яки корреспондентлык счетына күчерелә.

27. Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

субсидия алучы тарафыннан бирелгән документларның бу Тәртипнең 11 пункты нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы фактын билгеләү.

## VI. Йомгаклау нигезләмәләре

28. Субсидия алучы Министрлыкка агымдагы елның 31 декабренә кадәр килешүнең бертип формасына теркәлә торган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап бирә.

29. Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен мәҗбүри тикшерүне гамәлгә ашыра.

30. Субсидия алучы тарафыннан субсидия бирелгәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр факты буенча ачыкланган, шулай ук субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешелмәгән очракта, субсидия алучы алынган акчаны Министрлыкның язма таләпләрен алган көннән 30 календарь көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына тулы күләмдә кире кайтара.

31. Әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемен ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тартылган очракта, Министрлык субсидия алучының алынган акчаны Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарудан баш тарту турындагы хәбәрен алган көннән яки субсидия алучы алган һәм Министрлыкның язма таләбендә күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе законнары нигезендә ирекле рәвештә кире кайтару вакыты чыкканнан соң календарь көннәрдә исәпләнә торган җиде көн эчендә мәҗбүри тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

32. Субсидияне нәтиҗәле файдалануны, аны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2021 елда мәктәпкәчә мәгариф оешма-
ларында тәрбияләнүчеләр өчен татар
теленә өйрәтү буенча укыту-методик
комплектлар бастырып чыгаруга бәйле
чыгымнарны каплау өчен юридик затка
субсидия бирү тәртибенә кушымта

Форма

Теркәлү саны: ____________
Гариза теркәлү датасы: ____________

2021 елда мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләр өчен
татар теленә өйрәтү буенча укыту-методик комплектлар бастырып чыгаруга бәйле
чыгымнарны каплау өчен юридик затка субсидия бирүгә сайлап алуда катнашуга
заявка

| Оешма исеме | Җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) | Оешманың урнашу урыны, телефоны, электрон адресы |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

Оешма бу заявка нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елда мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләр өчен татар теленә өйрәтү буенча укыту-методик комплектлар бастырып чыгаруга бәйле чыгымнарны каплау өчен юридик затка субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 1 сентябрь, 805 нче карары белән расланган 2021 елда мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләр өчен татар теленә өйрәтү буенча укыту-методик комплектлар бастырып чыгаруга бәйле чыгымнарны каплау өчен юридик затка субсидия бирү тәртибенең 9 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый.

Оешма бу заявка нигезендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуда катнашучы буларак оешма турында, оешма тарафыннан бирелә торган заявка турында мәгълүмат, тиешле сайлап алуга бәйле оешма турында башка мәгълүмат бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгын раслый.

Кушымта: 1.
2.

Заявка бирүче ____________________________________/__________
(җитәкченең фамилиясе, инициаллары) (имзасы)

М.У.

_______________________________